**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# О комплексной системе мониторинга межнациональных и межконфессиональных отношений и раннего предупреждения конфликтов на религиозной и национальной почве в Республике Татарстан

В целях обеспечения межнационального и межконфессионального согласия на территории Республики Татарстан, раннего предупреждения конфликтов на религиозной и национальной почве, руководствуясь Стратегией государственной национальной политики Российской Федерации на период до 2025 года, утвержденной Указом Президента Российской Федерации от 19 декабря 2012 года № 1666 «О Стратегии государственной национальной политики Российской Федерации на период до 2025 года», **постановляю:**

1. Утвердить прилагаемое Положение о комплексной системе мониторинга межнациональных и межконфессиональных отношений и раннего предупреждения конфликтов на религиозной и национальной почве в Республике Татарстан.

2. Возложить на Министерство культуры Республики Татарстан:

осуществление сбора, хранения, обработки и анализа информации в рамках комплексной системы мониторинга межнациональных и межконфессиональных отношений и раннего предупреждения конфликтов на религиозной и национальной почве в Республике Татарстан (далее – комплексная система мониторинга);

осуществление взаимодействия с Академией наук Республики Татарстан по вопросам научно-методического обеспечения функционирования комплексной системы мониторинга;

выполнение функций по взаимодействию с федеральным органом исполнительной власти, осуществляющим мониторинг и анализ реализации государственной национальной политики в Российской Федерации.

3. Кабинету Министров Республики Татарстан:

разработать и утвердить в двухмесячный срок регламент информационного взаимодействия участников комплексной системы мониторинга;

представлять ежегодно Президенту Республики Татарстан доклад о результатах мониторинга межнациональных и межконфессиональных отношений и раннего предупреждения конфликтов на религиозной и национальной почве в Республике Татарстан;

привести свои акты в соответствие с настоящим Указом, а также принять иные решения по его реализации.

4. Рекомендовать главам городских округов и муниципальных районов Республики Татарстан:

определить структурное подразделение органа местного самоуправления, а также должностных лиц на уровне своих заместителей, ответственных за осуществление сбора, хранения, обработки и анализа информации в рамках комплексной системы мониторинга на территории соответственно городского округа или муниципального района Республики Татарстан;

обеспечить разработку и принятие мер по профилактике конфликтов на религиозной и национальной почве;

обеспечить представление информации в рамках комплексной системы мониторинга в Министерство культуры Республики Татарстан.

5. Предложить прокуратуре Республики Татарстан, Министерству внутренних дел по Республике Татарстан, Управлению Федеральной миграционной службы по Республике Татарстан, Территориальному органу Федеральной службы государственной статистики по Республике Татарстан обеспечить в пределах своей компетенции информационное взаимодействие участников комплексной системы мониторинга в соответствии с регламентом информационного взаимодействия.

6. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Временно исполняющий обязанности**
**Президента Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН * ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ *
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БҮЛЕК

Казань,Кремль
25 апреля 2015 года
№ УП-414

Утверждено
Указом Президента
Республики Татарстан

от «25» апреля 2015 года

№ УП - 414

**Положение**
**о комплексной системе мониторинга межнациональных и межконфессиональных отношений и раннего предупреждения конфликтов на религиозной и национальной почве в Республике Татарстан**

1. Настоящее Положение определяет цели, задачи, организационные и правовые основы комплексной системы мониторинга межнациональных и межконфессиональных отношений и раннего предупреждения конфликтов на религиозной и национальной почве в Республике Татарстан (далее – комплексная система мониторинга).

2. Комплексная система мониторинга представляет собой систему наблюдения за состоянием межнациональных и межконфессиональных отношений в Республике Татарстан (далее – система мониторинга), а также систему раннего предупреждения конфликтов на религиозной и национальной почве (далее также – система реагирования).

3. Система мониторинга включает в себя сбор, обработку, хранение и анализ информации о состоянии межнациональных и межконфессиональных отношений в Республике Татарстан. Ответственными за организацию системы мониторинга состояния межнациональных и межконфессиональных отношений в Республике Татарстан являются орган исполнительной власти Республики Татарстан, реализующий государственную политику и регулирующий отношения в сфере культуры, органы местного самоуправления в Республике Татарстан и их должностные лица, к компетенции которых отнесены вопросы профилактики межнациональных (межэтнических) конфликтов.

4. Система реагирования включает в себя деятельность государственных органов, органов местного самоуправления в Республике Татарстан и их должностных лиц по рассмотрению информации об угрозе возникновения конфликтов на религиозной или национальной почве и принятию в соответствии со своей компетенцией профилактических мер по раннему предупреждению таких конфликтов. Ответственными за организацию системы реагирования являются государственные органы, органы местного самоуправления в Республике Татарстан и их должностные

лица, к компетенции которых отнесены вопросы профилактики межнациональных (межэтнических) конфликтов.

5. Деятельность по мониторингу состояния межнациональных и межконфессиональных отношений в Республике Татарстан, а также раннему предупреждению конфликтов на религиозной и национальной почве осуществляется в соответствии с Конституцией Российской Федерации, федеральными законами, иными нормативными правовыми актами Российской Федерации, Конституцией Республики Татарстан, законами и иными нормативными правовыми актами Республики Татарстан, муниципальными нормативными правовыми актами.

6. Основной целью создания комплексной системы мониторинга является обеспечение межнационального и межконфессионального согласия на территории Республики Татарстан.

7. Основные задачи комплексной системы мониторинга:

а) комплексный анализ этнических, демографических и миграционных процессов, оценка и системное прогнозирование трансформации этнической структуры, расселения народов, состояния межнациональных и межконфессиональных отношений на республиканском и муниципальном уровнях;

б) обобщение и анализ результатов социологических исследований, информационного пространства, обращений граждан и опросов общественного мнения о состоянии межнациональных и межконфессиональных отношений;

в) оперативное реагирование на предконфликтные и конфликтные ситуации, их локализация, ликвидация последствий;

г) оценка эффективности проводимой в Республике Татарстан государственной национальной политики Российской Федерации, реализации полномочий государственных органов, органов местного самоуправления в Республике Татарстан и их должностных лиц по профилактике конфликтов на религиозной и национальной почве.

8. Участниками комплексной системы мониторинга являются:

Кабинет Министров Республики Татарстан;

Министерство культуры Республики Татарстан;

Управление записи актов гражданского состояния Кабинета Министров Республики Татарстан;

прокуратура Республики Татарстан (по согласованию);

Министерство внутренних дел по Республике Татарстан (по согласованию);

Управление Федеральной миграционной службы по Республике Татарстан (по согласованию);

Территориальный орган Федеральной службы государственной статистики по Республике Татарстан (по согласованию);

Республиканское агентство по печати и массовым коммуникациям «Татмедиа»;

Министерство информатизации и связи Республики Татарстан;

Министерство образования и науки Республики Татарстан;

Министерство труда, занятости и социальной защиты Республики Татарстан;

Министерство по делам гражданской обороны и чрезвычайным ситуациям Республики Татарстан;

Министерство экономики Республики Татарстан;

Министерство по делам молодежи и спорту Республики Татарстан;

органы местного самоуправления в Республике Татарстан (по согласованию);

Академия наук Республики Татарстан;

институты гражданского общества: общественные объединения, общественные и религиозные организации, представители экспертного сообщества, средства массовой информации (по согласованию).

9. Сбор первичной информации о состоянии межнациональных и межконфессиональных отношений в Республике Татарстан осуществляется из следующих источников:

а) социологические исследования о состоянии межнациональных и межконфессиональных отношений в Республике Татарстан;

б) информация правоохранительных органов о выявленных правонарушениях в сфере межнациональных и межконфессиональных отношений, а также причинах и условиях их совершения;

в) статистические сведения государственных органов, органов местного самоуправления в Республике Татарстан, информация общественных объединений, общественных и религиозных организаций, представителей экспертного сообщества о возможных конфликтах и предконфликтных ситуациях на религиозной и национальной почве;

г) данные мониторинга обращений граждан о конфликтных и предконфликтных ситуациях на религиозной и национальной почве и обстоятельствах, способствующих возникновению напряженности в сфере межнациональных отношений, в том числе принимаемые через систему обеспечения вызова экстренных служб по единому номеру «112» и государственную информационную систему Республики Татарстан «Народный контроль»;

д) данные мониторинга информационного пространства (публикаций и сообщений в средствах массовой информации, информационно-телекоммуникационной сети «Интернет»);

е) данные мониторинга выполнения государственных программ, связанных с реализацией государственной национальной политики Российской Федерации.

10. Участники комплексной системы мониторинга представляют информацию в орган исполнительной власти Республики Татарстан, реализующий государственную политику и регулирующий отношения в сфере культуры в соответствии с регламентом информационного

взаимодействия, утверждаемым Кабинетом Министров Республики Татарстан.

11. Обработка, хранение и анализ информации в рамках комплексной системы мониторинга осуществляется органом исполнительной власти Республики Татарстан, реализующим государственную политику и регулирующим отношения в сфере культуры с использованием государственных информационных систем. Органы местного самоуправления в Республике Татарстан используют государственные информационные системы на основе соглашений и при необходимости обеспечения реализации полномочий по профилактике межнациональных (межэтнических) конфликтов создают муниципальные информационные системы.

12. Система раннего предупреждения конфликтов на религиозной и национальной почве обеспечивает:

а) межведомственный информационный обмен по вопросам межнациональных и межконфессиональных отношений;

б) координацию межведомственного взаимодействия в целях предотвращения и урегулирования конфликтных ситуаций в сфере межнациональных отношений;

в) разработку и (или) экспертизу мероприятий по гармонизации межнациональных отношений, в том числе по устранению причин и условий, способствующих возникновению межнациональных конфликтов, организацию их реализации;

г) рассмотрение и анализ результатов ведомственного мониторинга в сфере межнациональных отношений;

д) координацию взаимодействия со средствами массовой информации в целях оперативного информирования населения о развитии конфликтных ситуаций, о принимаемых мерах по их ликвидации для снижения рисков преднамеренного обострения таких ситуаций;

е) организацию взаимодействия территориальных органов федеральных органов исполнительной власти, органов исполнительной власти Республики Татарстан, органов местного самоуправления в Республике Татарстан с общественными объединениями, общественными и религиозными организациями в сфере гармонизации межнациональных отношений;

ж) подготовку предложений по актуальным вопросам межнациональных отношений для рассмотрения на заседаниях республиканских совещательных и координационных органов;

з) подготовку практических предложений, способствующих принятию обоснованных управленческих решений в процессе выработки мер по предотвращению межнациональной, межконфессиональной напряженности и конфликтов;

и) подготовку информационных материалов, способствующих гармонизации межнациональных отношений, для размещения в средствах массовой информации.

13. Орган исполнительной власти Республики Татарстан, реализующий государственную политику и регулирующий отношения в сфере культуры, ежегодно формирует доклад о результатах мониторинга межнациональных и межконфессиональных отношений и раннего предупреждения конфликтов на религиозной и национальной почве в Республике Татарстан (далее – доклад) и не позднее 25 января года, следующего за отчетным, представляет в Кабинет Министров Республики Татарстан.

14. Кабинет Министров Республики Татарстан ежегодно в срок до 10 февраля года, следующего за отчетным, вносит доклад Президенту Республики Татарстан.

15. Президентом Республики Татарстан по итогам рассмотрения доклада могут быть даны поручения государственным органам и организациям для принятия мер по реализации предложений, содержащихся в докладе.

**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасында милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрне, дини һәм милли җирлектәге низагларны алдан кисәтүне комплекслы мониторинглау системасы турында**

Татарстан Республикасы территориясендә милләтара һәм конфессияара татулыкны тәэмин итү, дини һәм милли җирлектәге низагларны алдан кисәтү максатларында, Россия Федерациясе Президентының «2025 елга кадәрге чорга Россия Федерациясе дәүләт милли сәясәте стратегиясе турында» 2012 елның 19 декабрендәге 1666 номерлы Указы белән расланган 2025 елга кадәрге чорга Россия Федерациясе дәүләт милли сәясәте стратегиясенә нигезләнеп, **карар бирәм:**

1. Кушымтада бирелүче Татарстан Республикасында милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрне, дини һәм милли җирлектәге низагларны алдан кисәтүне комплекслы мониторинглау системасы турында нигезләмәне расларга.

2. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына түбәндәгеләрне йөкләргә:

Татарстан Республикасында милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрне, дини һәм милли җирлектәге низагларны алдан кисәтүне комплекслы мониторинглау системасы (алга таба – комплекслы мониторинглау системасы) кысаларында мәгълүмат җыюны, аны саклауны, эшкәртүне һәм анализлауны башкаруны;

комплекслы мониторинглау системасының эшләвен фәнни-методик яктан тәэмин итү буенча Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе белән хезмәттәшлек итүне;

Россия Федерациясендә дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыруны мониторинглау һәм анализлауны гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органы белән үзара хезмәттәшлек итү функцияләрен башкаруны.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына:

ике ай эчендә комплекслы мониторинглау системасында катнашучыларның мәгълүмати үзара хезмәттәшлеге регламентын эшләргә һәм расларга;

Татарстан Республикасы Президентына ел саен Татарстан Республикасында милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрне, дини һәм милли җирлектәге низагларны алдан кисәтүне мониторинглау йомгаклары турында доклад бирергә;

үз актларын әлеге Указга туры китерергә, шулай ук аны гамәлгә ашыру буенча башка карарлар кабул итәргә.

4. Татарстан Республикасы шәһәр округлары һәм муниципаль районнары башлыкларына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

җирле үзидарә органының Татарстан Республикасының тиешле шәһәр округы һәм муниципаль районы территориясендә комплекслы мониторинглау системасы кысаларында мәгълүмат җыюны, аны саклауны, эшкәртүне һәм анализлауны башкару өчен җаваплы структур бүлекчәсен, шулай ук үз урынбасарларыннан вазыйфаи затларны билгеләргә;

дини һәм милли җирлектәге низагларны кисәтү буенча чаралар эшләүне һәм кабул итүне тәэмин итәргә;

комплекслы мониторинглау системасы кысаларында мәгълүматны Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына тапшыруны тәэмин итәргә.

5. Татарстан Республикасы прокуратурасына, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына, Федераль миграция хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә, Федераль дәүләт статистика хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органына комплекслы мониторинглау системасында катнашучыларның мәгълүмати үзара хезмәттәшлеге регламенты нигезендә үз компетенцияләре чикләрендә мәгълүмати хезмәттәшлекне тәэмин итү тәкъдиме ясарга.

6. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты вазыйфаларын вакытлыча башкаручы** **Р.Н. Миңнеханов**

ГОМУМИ БҮЛЕК / ОБЩИЙ ОТДЕЛ — ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан,Кремль
2015 ел, 25 апрель
№ ПУ-414

Татарстан Республикасы
Президентының
2015 елның «25» апрелендәге
ПУ-414 номерлы Указы белән
расланды

**Татарстан Республикасында милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрне, дини һәм милли җирлектәге низагларны алдан кисәтүне комплекслы мониторинглау системасы турында нигезләмә**

1. Әлеге Нигезләмәдә Татарстан Республикасында милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрне, дини һәм милли җирлектәге низагларны алдан кисәтүне комплекслы мониторинглау системасының (алга таба – комплекслы мониторинглау системасы) максатлары, бурычлары, оештыру һәм хокукый нигезләре билгеләнә.

2. Комплекслы мониторинглау системасы Татарстан Республикасында милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрнең торышына күзәтчелек итү системасы (алга таба – мониторинглау системасы), шулай ук дини һәм милли җирлектәге низагларны алдан кисәтү системасы (алга таба шулай ук – чара күрү системасы) булып тора.

3. Мониторинглау системасын Татарстан Республикасында милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр торышы турындагы мәгълүматны җыю, эшкәртү, саклау һәм анализлау тәшкил итә. Татарстан Республикасында милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр торышын мониторинглау системасын оештыру өчен мәдәният өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыручы һәм мөнәсәбәтләрне җайга салучы Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы, компетенцияләренә милләтара (этносара) низагларны кисәтү мәсьәләләре кертелгән Татарстан Республикасында җирле хакимият органнары һәм аларның вазыйфаи затлары җаваплы була.

4. Чара күрү системасын дәүләт органнарының, Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарының һәм аларның вазыйфаи затларының дини яисә милли җирлектә низаглар килеп чыгу куркынычы турындагы мәгълүматны карап тикшерү һәм үз компетенцияләре нигезендә мондый низагларны алдан кисәтү буенча профилактика чаралары күрү эшчәнлеге тәшкил итә. Чара күрү системасын оештыру өчен компетенцияләренә милләтара (этносара) низагларны профилактикалау мәсьәләләре кергән дәүләт органнары, Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары һәм аларның вазыйфаи затлары җаваплы була.

5. Татарстан Республикасында милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр торышын мониторинглау, шулай ук дини һәм милли җирлектәге низагларны алдан кисәтү буенча эшчәнлек Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы Конституциясе, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары, муниципаль норматив хокукый актлар нигезендә башкарыла.

6. Комплекслы мониторинглау системасын булдыруның төп максаты – Татарстан Республикасы территориясендә милләтара һәм конфессияара татулыкны тәэмин итү.

7. Комплекслы мониторинглау системасының төп бурычлары түбәндәгеләр:

а) этник, демографик һәм миграция процессларына комплекслы анализ ясау, этник структураның трансформациясен, халыкларның урнашуын, республика дәрәҗәсендә һәм муниципаль дәрәҗәдә милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр торышын бәяләү һәм системалы фаразлау;

б) милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр торышы турында социологик тикшеренүләр йомгакларын, мәгълүмати мәйданны, гражданнар мөрәҗәгатьләре һәм җәмәгать фикерен сораштыруны гомумиләштерү һәм анализлау;

в) низаг алдыннан була торган һәм низаглы хәлләргә карата оператив рәвештә чаралар күрү, аларның таралышын туктату, нәтиҗәләрен бетерү;

г) Татарстан Республикасында уздырыла торган Россия Федерациясе дәүләт милли сәясәтенең, дәүләт органнарының, Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары һәм аларның вазыйфаи затларының дини һәм милли җирлектә низагларны кисәтү буенча үз вәкаләтләрен башкаруы нәтиҗәлелегенә бәя бирү.

8. Комплекслы мониторинглау системасында катнашучылар түбәндәгеләр:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты;

Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Граждан хәле актларын теркәү идарәсе;

Татарстан Республикасы прокуратурасы (килешү буенча);

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы (килешү буенча);

Федераль миграция хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе;

Дәүләт статистикасы буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча территориаль органы (килешү буенча);

Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы;

Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы;

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы;

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы;

Татарстан Республикасы Граждан оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы;

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы;

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы;

Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары (килешү буенча);

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе;

граждан җәмгыяте институтлары: җәмәгать берләшмәләре, иҗтимагый һәм дини оешмалар, экспертлар берләшмәләре вәкилләре, массакүләм мәгълүмат чаралары (килешү буенча).

9. Татарстан Республикасында милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрнең торышы турындагы беренчел мәгълүматны җыю түбәндәге чыганаклардан гамәлгә ашырыла:

а) Татарстан Республикасында милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрнең торышы турында социологик тикшеренүләр;

б) Татарстан Республикасында милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр өлкәсендә ачыкланган хокук бозулар турында, шулай ук аларның кылынуы сәбәпләре һәм шартлары турында хокук саклау органнары мәгълүматы;

в) милли һәм дини җирлектә килеп чыгуы мөмкин булган низаглар һәм низаг алдыннан була торган хәлләр турында дәүләт органнарының, Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарының статистик белешмәләре, иҗтимагый берләшмәләрнең, иҗтимагый һәм дини оешмаларның, экспертлар берләшмәләре вәкилләренең мәгълүматлары;

г) гражданнарның дини һәм милли җирлектә низаглы һәм низаг алдыннан була торган хәлләр һәм милләтара мөнәсәбәтләр өлкәсендә киеренкелек тууга этәргеч бирә торган, шул исәптән «112» бердәй номеры буенча ашыгыч хезмәтләрне чакыртуны тәэмин итү системасы һәм Татарстан Республикасының «Халык контроле» дәүләт мәгълүмати системасы аша кабул ителә торган мөрәҗәгатьләрен мониторинглау күрсәткечләре;

д) мәгълүмати мәйданны (массакүләм мәгълүмат чараларындагы, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге мәкаләләр һәм язмаларны) мониторинглау күрсәткечләре;

е) Россия Федерациясе дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру белән бәйле дәүләт программаларын үтәүне мониторинглау күрсәткечләре.

10. Комплекслы мониторинглау системасында катнашучылар мәгълүматны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана торган мәгълүмати үзара хезмәттәшлек турындагы регламент нигезендә мәдәният өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыра һәм

мөнәсәбәтләрне җайга сала торган Татарстан Республикасы башкарма хакимият органына тапшыра.

11. Комплекслы мониторинглау системасы кысаларында мәгълүматны эшкәртү, саклау һәм анализлау дәүләт мәгълүмат системаларын файдаланып мәдәният өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыра һәм мөнәсәбәтләрне җайга сала торган Татарстан Республикасы башкарма хакимият органы тарафыннан башкарыла. Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары дәүләт мәгълүмати системаларыннан килешү нигезендә файдаланалар һәм милләтара (этносара) низагларны кисәтү буенча вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тәэмин итү зарурлыгы туганда, муниципаль мәгълүмат системалары булдыралар.

12. Дини һәм милли җирлектә низагларны алдан кисәтү системасы түбәндәгеләрне тәэмин итә:

а) милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр мәсьәләләре буенча ведомстволар арасында мәгълүмат алмашуны;

б) милләтара мөнәсәбәтләр өлкәсендә низаглы хәлләрне булдырмау һәм җайга салу максатларында ведомствоара хезмәттәшлекне координацияләүне;

в) милләтара мөнәсәбәтләрне каршылыксыз итү, шул исәптән милләтара низагларның килеп чыгуына этәргеч бирүче сәбәпләр һәм шартларны бетерү буенча чаралар эшләүне һәм (яисә) аларга экспертиза уздыруны, аларны гамәлгә ашыруны оештыруны;

г) милләтара мөнәсәбәтләр өлкәсендә ведомство уздырган мониторинглау нәтиҗәләрен карап тикшерүне һәм анализлауны;

д) халыкка низаглы хәлләрнең барышы, аларны бетерү буенча күрелә торган чаралар, аларны алдан белеп кискенләштерү куркынычын киметү турында оператив мәгълүмат бирү максатларында массакүләм мәгълүмат чаралары белән хезмәттәшлекне координацияләүне;

е) милләтара мөнәсәбәтләрне каршылыксыз итү өлкәсендә федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары, Татарстан Республикасында җирле хакимият органнарының җәмәгать берләшмәләре, иҗтимагый һәм дини оешмалар белән үзара хезмәттәшлеген оештыруны;

ж) республиканың киңәшмә һәм координация органнары утырышларында милләтара мөнәсәбәтләрнең актуаль мәсьәләләрен карап тикшерү турында тәкъдимнәр әзерләүне;

з) милләтара, конфессияара киеренкелекне һәм низагларны булдырмау чараларын эшләү барышында нигезле идарә карарларын кабул итүгә булышлык итүче гамәли тәкъдимнәр әзерләүне;

и) милләтара мөнәсәбәтләрне җайга салуга ярдәм итүче мәгълүмати материалларны массакүләм мәгълүмат чараларында бастыру өчен әзерләүне.

13. Мәдәният өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыручы һәм мөнәсәбәтләрне җайга салучы Татарстан Республикасы башкарма хакимият органы ел саен Татарстан Республикасында милләтара һәм конфессияара

мөнәсәбәтләрне, дини һәм милли җирлектәге низагларны алдан кисәтүне комплекслы мониторинглау нәтиҗәләре турында доклад (алга таба – доклад) әзерли һәм хисап елыннан соң килә торган елның 25 гыйнварыннан да соңга калмыйча, аны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына тапшыра.

14. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты ел саен хисап елыннан соң килә торган елның 10 февраленә кадәр доклад тапшыра.

15. Докладны карап тикшерү йомгаклары буенча Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан дәүләт органнары һәм оешмаларына докладтагы тәкъдимнәрне гамәлгә ашыру буенча чаралар күрү турында йөкләмәләр бирелергә мөмкин.